МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.06.2019 г. Казань № под-894/19

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламентын раслау турында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә боерык бирәм:

1. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламентын (кушымтада бирелә) раслагра.
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) боерыкны имзалаганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
05.06.2019 № под-894/19 боерыгы
белән расланды

**Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгеләи.

1.2. Хезмәт алучылар: Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы балаларны вакытлыча кабул итәргә теләгән балигъ гражданнар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы _____________________ муниципаль районының (шәһәр округының) опека һәм попечительлек органы (алга таба – опека һәм попечительлек органы) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Опека һәм попечительлек органы урнашкан урын: ___________________, _________________ ур., ____ й., ___ каб.

Опека һәм попечительлек органының эш графигы: көн саен, шимбә, якшәмбедән кала, ______ башлап ______ кадәр, төшке аш ____ башлап _______ кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы ____________________________________________.

Җәмәгать транспортында ____________ тукталышына кадәр килергә кирәк.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә (яки – ирекле).

1.3.2. Белешмә телефоннары: ________________________.

1.3.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитетының рәсми сайты адресы: http://www.________.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай опека һәм попечительлек органы урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алучы, Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитетының мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://www.__________ tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) опека һәм попечительлек органына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) опека һәм попечительлек органына язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты рәсми сайтында (http://www.__________.tatarstan.ru) һәм Башкарма комитетның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында опека һәм попечительлек органы белгече тарафыннан урнаштырыла.

1.3.6. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4., 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы);

Россия Федерациясе Гаилә кодексы (алга таба – РФ Гаилә кодексы);

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Российская газета, 2010, 30 июль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, 2011, 08 апрель, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – РФ Президентының 601 номерлы Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында» 2009 елның 19 маендагы 432 номерлы карары (алга таба – 432 номерлы Кагыйдәләр) белән расланган Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру кагыйдәләре (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, №21, 2581 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Ятим балаларны һәм

ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка), опекага (попечениегә), тәрбиягә яки патронат гаиләгә алу нияте булган гражданнарга медицина таныклавын уздыру тәртибен, шулай ук мондый гражданнарга медицина таныклавын уздыру турында бәяләмә формасын раслау турында» 2014 елның 18 июнендәге 290н номерлы боерыгы (алга таба – 290н номерлы Боерык) (Российская газета, 2014, 18 август);

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру буенча аерым мәсьәләләрне гамәлгә ашыру турында» 2019 елның 16 гыйнварындагы 17 номерлы боерыгы (алга таба – 17 номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 16 апрель, бастырып чыгару номеры: 0001201904160065);

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба – ТР Гаилә кодексы);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2004, № 2, 70 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2008, № 3, 212 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

20 ___ елның _________ № ________ ___________________________________ белән расланган ______________________________ устав (алга таба – Устав);

Татарстан Республикасы _____________________________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты турында 20 ____ елның ___________ № ________ нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

Башкарма комитетның 20____ елның _____________ № ______ карары белән расланган _______________ муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге турында нигезләмә (алга таба – Бүлек турында нигезләмә);

20___ елның ________ № ____ белән расланган Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре).

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәте – федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының, җирле үзидарә органының

функцияләрен тормышка ашыру эшчәнлеге, ул дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чигендә мөрәҗәгать итүчеләрнең гарызнамәләре буенча гамәлгә ашырыла;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 11 өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда мөрәҗәгать итүченең бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле гарызнамә белән яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән гарызнамә белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турында килешүгә туры китереп күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләрне кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла. Гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | | торган норматив акт |
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ граждannар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү | РФ Гаилә кодексының $155^2$ ст.;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законының 5 ст.<br>432 номерлы Кагыйдәләр |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган органның аталышы | Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы ______________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге | 8-ТРЗ номерлы ТР Законының 5 ст. |
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Баланы (балаларны) гражданин гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә яки, сәбәпләрен күрсәтеп, аны бирүдән язмача баш тарту | 432 номерлы Кагыйдәләрнең 12 п.; |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты | Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап 17 эш көне.<br>Әлеге вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 7 көннән дә артык түгел, опека һәм попечительлек органы тарафыннан 432 номерлы Кагыйдәләрнең 13, 16 пунктларында күрсәтелгән документлар алынганчыга кадәр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган | 432 номерлы Кагыйдәләрнең 11, 12, 18 п. |
| 2.5. Дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүче | 1) гариза (1 нче кушымта);<br>2) паспорт яки шәхес таныклаучы башка документ күчермәсе (төп нөсхәсен күрсәтеп);<br>3) гражданинда ачык формадагы йогышлы авыруларның яки психик авыруларның, наркомания, токсикомания, эчкечелек авыруларының булмавы турында дәва-профилактика медицина | 432 номерлы Кагыйдәләр<br>17 номерлы боерык |

| | | |
|---|---|---|
| тарафыннан тапшырылырга тиешле кирәкле документларның тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | оешмасыннан белешмә йә ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка), опекага (попечениегә), тәрбиягә яки патронат гаиләгә алырга ният белдергән гражданнарга медицина таныклавын уздыру нәтиҗәләре турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән тәртиптә рәсмиләштерелгән бәяләмә (2 нче кушымта).<br>3 пунктчада күрсәтелгән документлар бирелгән көннән соң 6 ай эчендә гамәлдә була.<br>Гражданин үзендә балалар тәрбияләүдә кирәкле белемнәр һәм күнекмәләр булуы турында таныклый торган бүтән документларны, шул исәптән белем һәм (яки) квалификация турында документларны, эш урыныннан биләгән вазыйфасы турында белешмәне, Россия Федерациясе территориясендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итү нияте булган затлар өчен әзерлек узу турында таныклык күчермәсен тапшырырга хокуклы.<br>Дәүләт хезмәтен алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче опека һәм попечительлек органына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәгечә тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>- опека һәм попечительлек органына түбәндәге алымнарның берсе белән кәгазьдә:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат | 290н номерлы боерык |

| | | |
|---|---|---|
| | тарафыннан);<br>почта юлламасы белән;<br>- көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә «Интернет» челтәре аша (алга таба төп нөсхәләрен тапшырып), түбәндәгеләрдән файдаланып:<br>Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан;<br>Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан;<br>Башкарма комитет сайтыннан;<br>- КФҮ аша.<br>Гражданин опека һәм попечительлек органына шәхси мөрәҗәгать иткән очракта гариза биргәндә паспортын яки шәхес таныклаучы башка документын күрсәтә.<br>Әгәр гражданинның яшәеш шартларын тикшергәндә баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә, аның физик һәм әхлакый үсешенә куркыныч тудыручы яисә тудыра алган яки аның хокукларын һәм закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен боза алган хәлләр булуы ачыкланса, опека һәм попечительлек органы өстәмә рәвештә гражданиннан түбәндәгеләрне язмача соратып алырга хокуклы:<br>а) бала вакытлыча торачак торак урынына карата гражданинның файдалану хокукын яки милек хокукын раслый торган документларның күчермәләрен;<br>б) гражданин белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларында ачык формада йогышлы авыруларның, психик тайпылышларның һәм диспансерда күзәтү тәмамланганчыга кадәр үз-үзенең | |

| | | |
|---|---|---|
| | тотышында тайпылышлары булмавы турында дәва-профилактика учреждениесеннән белешмә. Белешмә урынына гражданинның гаилә әгъзалары дәва-профилактика учреждениесеннән 164/у формасы буенча бирелгән медицина бәяләмәсен тапшыра ала. Әлеге документлар опека һәм попечительлек органына бирелгән көненнән алып 6 ай эчендә кабул ителә. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; шушы документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына: хөкем ителгән булуы (булмавы) һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты турында яисә шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена, шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә карата, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, шулай ук җәмәгать иминлегенә, татулыкка һәм кешелеклелекнең куркынычсызлыгына карата; авыр яки аеруча авыр җинаятьләр өчен җинаять өчен җинаять эзәрлекләвен туктату турында эчке эшләр органнарыннан белешмә; бала (балалар) вакытлыча торачак торак урын гражданинның яшәү урыны булып тормаган очракларда, мөрәҗәгать итүченең тору урыны буенча яшәеш шартларын тикшерү акты – гражданинның яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы таләбе буенча тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә гражданин торган урын буенча опека һәм попечительлек органы тарафыннан төзелгән; (яше буенча пенсионерларның, инвалидлык буенча, тукландыручыны югалту очрагы буенча) ай саен алына торган | РФ Гаилә кодексының 146 ст.; 432 номерлы Кагыйдәләр |

| | | |
|---|---|---|
| | акчалата түләүләр күләме турында белешмәләр.<br>Әгәр гражданинның яшәеш шартларын тикшергәндә баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы яисә тудыра алган хәлләр, аның физик һәм әхлакый үсешенә куркыныч тудыручы яки аның хокукларын һәм закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен боза алган хәлләр булуы ачыкланса, опека һәм попечительлек органы ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсенең вәкаләтле органнарыннан баланы (балаларны) үз гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсен алу нияте булган гражданин яшәгән урын буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләрне раслау турында сорый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документларны, шулай ук кабул итүдән яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында «а»-«г» пунктчаларында санап үтелгән очраклардан тыш. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>2. Фактик яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәү | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән кире кагыла:<br>1. опека һәм попечительлек органына мөрәҗәгать иткән гражданин(нар)га, – мөрәҗәгать итүче(ләр) түбәндәге категориягә караган очракларда:<br>а) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки чикләнгән рәвештә эшкә сәләтсез дип танылган затлар;<br>б) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән яки ата-ана хокукларында чикләнгән затлар;<br>в) элек уллыкка алучы затлар, әгәр уллыкка алу алар гаебе нигезендә суд тарафыннан гамәлдән чыгарылган булса;<br>г) законда йөкләнгән бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән затлар;<br>д) суд хөкеменә ия яки суд хөкемендә булган, шәхеснең | 432 номерлы Кагыйдәләр |

| | | |
|---|---|---|
| | гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена (законсыз рәвештә психиатрия стационарына урнаштырудан, нахак ягудан һәм мыскыл итүдән тыш), шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә карата, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗимагый әхлаклылыкка каршы, җәмәгать иминлегенә каршы җинаять эзәрлекләвенә дучар ителүче яки дучар ителгән булган затлар (тернәкләндерү нигезләре буенча үзләренә карата җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш), шулай ук авыр яки аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яки үтәлмәгән хөкеме булган затлар;<br>е) ачык формадагы йогышлы авырулары яки психик авырулары булган, наркомания, токсикомания, эчкечелек белән авыручы затлар;<br>ж) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәү урыны булмаган затлар;<br>2. мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү хокукын билгеләү нигезе булып торучы документлар тиешенчә рәсмиләштерелмичә, тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырылганда;<br>3. баланы (балаларны) гражданин гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә рәсмиләштергән вакытка әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның төп нөсхәләренең опека һәм попечительлек органында булмавы баланы (балаларны) гражданин гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирүдән баш тарту нигезе булып тора.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүне | |

| | | |
|---|---|---|
| | туктату өчен нигезләр юк. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм аны алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының 601 номерлы Указының 1 пункты |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү вакыты | Гариза кергән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны | Дәүләт хезмәте янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле булган мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә | |

| | | |
|---|---|---|
| социаль яклау турындагы законнары нигезендә аталган объектларның үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлек итү саны һәм аларның озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләреннән файдаланып, алу мөмкинлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>бинаның җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаларны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен тапшырганда | |

| | | |
|---|---|---|
| | чиратларның;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылулар;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезле шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәтен күрсәткән муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә бәйләнешкә керүе күздә тотыла. Үзара хезмәттәшлек итүнең вакыт озынлыгы регламентта билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ), КФҮ читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелгәндә, консультацияләүне, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Башкарма комитетның рәсми сайтыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, КФҮ алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация Интернет-кабул итү аша бирелә.<br>Электрон формалы гариза һәм документлар Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы, Татарстан Республикасы Дәүләт | 432 номерлы Кагыйдәләр<br>63-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Башкарма комитетның рәсми сайты аша, алга таба баланы (балаларны) гражданин гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә рәсмиләштерү өчен документларның төп нөсхәләрен тапшырып, җибәрелә. | |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедуралардан тора:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү;

2) мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документларны кабул итү;

3) ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

4) документларны, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерү;

5) мөрәҗәгать итүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү (3 нче кушымта);

6) ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә әзерләү;

7) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (4 нче кушымта);

8) нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү;

9) техник хатаны төзәтү;

10) дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны аша күрсәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе, телефон, электрон почта аша (адресы: ________________) һәм (яки) хат белән дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен опека һәм попечительлек органына мөрәҗәгать итә.

Опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм

эчтәлеге буенча, консультация бирә. Бланкны тутырганда зарурлык булганда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләү, кисәтүләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документларны кабул итү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән, почта аша, «Интернет» челтәре аша Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (адресы: ___________) аша Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (адресы:__________), Башкарма комитет сайты (адресы:____________), КФҮ аша әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, электрон формада гариза тапшырыла (җибәрелә).

3.3.2. Опека һәм попечительлек органының кабул итүне гамәлгә ашыручы белгече:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә (документларның күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүен, документларда чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган урыннарның һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтү урыннарының булу-булмавын) туры килү-килмәвен тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаганда, опека һәм попечительлек органы белгече гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны терки.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итеп алудан баш тарту нигезләре булган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәүдән баш тарту өчен каршылыклар булуы хакында шәхсән хәбәр итә һәм аңа, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кайтарып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул итеп алынган документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы яки мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар.

3.4. Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. Опека һәм попечительлек органы, гариза бирелгән көннән алып 2 көнлек срокта ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы билгеләгән формада әлеге Регламентның 2.6 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән белешмәләрне эчке эшләр органнарыннан сората.

3.4.2. Опека һәм попечительлек органының белешмәләр бирү турындагы гарызнамәсенә җаваплар вәкаләтле органыннан опека һәм попечительлек органына законнарда билгеләнгән вакытта җибәрелә.

Опека һәм попечительлек органы гарызнамәсенә җавап бирү формасы һәм тәртибен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы билгели.

Гражданнар тарафыннан гаризада күрсәтелгән хөкем ителгәнлек булуы (булмавы) турындагы белешмәләр бер елдан күбрәк элек расланган булса, баланың (балаларның) яшәү (тору) урыны буенча опека һәм попечительлек органы тиешле вәкаләтле органнардан мондый белешмәләрне раслау турында кабат сорый.

Процедураларның нәтиҗәсе: гарызнамәләргә җавап нәтиҗәсе булып торучы белешмәләр, мәгълүматлар (документлар) бирү турында җибәрелгән гарызнамәләр яки соралучы белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәр.

3.5. Опека һәм попечительлек органы белгече тапшырылган документларны тикшерә һәм әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуын (булмавын) билгели.

Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече:

баш тарту турында хат әзерли һәм имзаланган датадан башлап 3 көнлек срокта аны мөрәҗәгать итүчегә җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә барлык документлар да кире кайтарыла, карарга шикаять белдерү тәртибе аңлатыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедураны үткәрү турында карар кабул итү яки баш тарту турында хат әзерләү.

3.6. Мөрәҗәгать итүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү.

3.6.1. Баланы (балаларны) үзенә вакытлыча тапшыру турында ният белдергән гражданинның яшәеш шартларына тикшерү уздыру өчен мөрәҗәгать итүчене торак-көнкүреш шартлары, аның баланы тәрбияләү мотивлары, сәләте; мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзалары арасында барлыкка килгән мөнәсәбәтләр тикшерелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамланган көннән соң ике эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү.

3.6.2. Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданинның яшәеш шартларын тикшерү акты рәсмиләштерелә, ул тикшерү үткәргән затларның имзалары белән таныклана.

Әгәр гражданинның яшәеш шартларын тикшергәндә баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә, аның физик һәм әхлакый үсешенә куркыныч тудыручы яисә тудыра алган яки аның хокукларын һәм закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен боза алган хәлләр булуы ачыкланса, опека һәм попечительлек органы:

- гражданиннан язмача формада түбәндәгеләрне өстәмә соратып алырга хокуклы:

а) бала вакытлыча торачак торак урынына карата гражданинның файдалану хокукын яки милек хокукын раслый торган документларның күчермәләрен;

б) гражданин белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларында ачык формада йогышлы авыруларның, психик тайпылышларның булмавы турында дәва-профилактика учреждениесеннән белешмә. Белешмә урынына гражданинның гаилә әгъзалары дәва-профилактика учреждениесеннән 164/у формасы буенча бирелгән медицина бәяләмәсен тапшыра ала. Әлеге документлар опека һәм попечительлек органына бирелгән көненнән алып 6 ай эчендә кабул ителә.

- гариза бирелгән көннән алып 2 эш көне дәвамында тиешле вәкаләтле органнардан баланы (балаларны) үз гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсен алырга теләгән гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән граждannар турында белешмәләрне раслауны сорый.

Ведомствоара гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында җибәрелә.

Баланы (балаларны) үз гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсен алырга теләгән гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән граждannар турында белешмәләрне раслау турында опека һәм попечительлек органы гарызнамәсенә җавап вәкаләтле органнан опека һәм попечительлек органына тиешле гарызнамә алынган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта җибәрелә.

3.6.3. Бала (балалар) вакытлыча торачак торак урын гражданинның яшәү урыны булып тормаса, гражданин яшәгән урын буенча опека һәм попечительлек органы гражданинның тору урыны буенча опека һәм попечительлек органына аның тору урыны буенча гражданинның яшәеш шартларын тикшерү актын рәсмиләштерү турында гарызнамә җибәрә яки гражданинның кулына тапшыра.

Гражданин торган урын буенча опека һәм попечительлек органы гарызнамә нигезендә, гражданинның торак-көнкүреш шартларын, гражданинның гаилә әгъзалары арасында барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне бәяләү максатларында, гражданинның һәм аның гаиләсенең яшәеш шартларына тикшерү уздыра һәм торган урыны буенча гражданинның яшәеш шартларын тикшерү актын 3 нөсхәдә рәсмиләштерә, аларның берсе имзаланган датасыннан соң 3 көн узганчы гражданинга җибәрелә, икенчесе гарызнамә җибәргән опека һәм попечительлек органына җибәрелә яки яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына тапшыру өчен гражданинның кулына тапшырыла, өченчесе гражданинның тору урыны буенча опека һәм попечительлек органында саклана.

Процедураларның нәтиҗәсе: балаларны үзенә вакытлыча тапшыру турында ният белдергән гражданинның яшәеш шартларын тикшерү актын төзү (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы) яки 3.6.2, 3.6.3 пунктларда күрсәтелгән документларны язмача сорату.

Гражданинның яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы тарафыннан гражданин гаиләсенә баланы (балаларны) вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмәне рәсмиләштерү срогы әлеге Регламентның 3.6.2, 3.6.3 пунктларында күрсәтелгән документларны опека һәм попечительлек органы алганчыга кадәр озайтылырга мөмкин, ләкин иң күбе 7 көнгә генә.

3.6.4. Опека һәм попечительлек органы белгече алынган барлык белешмәләрне исәпкә алып, әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булган очракта, опека һәм попечительлек органы белгече баш тарту турында хат әзерли һәм кул куелган датадан башлап 3 көн эчендә аны мөрәҗәгать итүчегә җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә барлык документларны кире кайтара һәм карарга шикаять белдерү тәртибен аңлата һәм әлеге Регламентның 3.9 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза килгән вакыттан башлап

бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны актыкка тикшерү һәм бәяләмә әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.7. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә әзерләү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек органы белгече, тапшырылган документлар нигезендә, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы балаларны вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә яки, алга таба опека һәм попечительлек органы җитәкчесеннән раслатып, баш тарту турында хат әзерли.

Әгәр гражданинның яшәү урыны буенча торак урыны тиешле торак пункты шартларына карата төзекләндерелмәгән булса яисә әлеге торак урында балаланың торуы аның сәламәтлегенә, физик һәм әхлакый үсешенә куркыныч тудырса, гражданинның яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы, әлеге торак урынында тормыйча, гражданинга баланы (балаларны) вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә рәсмиләштерергә хокуклы. Шул ук вакытта гражданин:

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасының көн тәртибенә туры китереп, баланы (балаларны) көндезге сәгатьләрдә алырга мөмкин;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасына туристик юлламаны күрсәтеп, шифаханә-курорт дәвасы һәм ял, дәвалау-савыктыру, физкультура-спорт һәм башка билгеләнештәге объектлар территориясендә урнашып, бала (балалар) белән ял итү (савыгу) өчен чыгып китәргә мөмкин;

бала (балалар) белән гражданинның яшәү урыны булып тормаган торак урынында яшәргә мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торган балаларны вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә яки 3.9 п. нигезендә әзерләнгән баш тарту турында хат.

3.8. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.8.1. Опека һәм попечительлек органы белгече, имзаланган бәяләмәне алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүчегә хат бирә (җибәрә). Тискәре нәтиҗә булган очракта, баш тарту турындагы хатны шәхсән кулына тапшыра яки белдерүле заказлы хат белән почта аша 3.9 п. нигезендә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура 3.7.1 пунктчада каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү.

3.9.1. Опека һәм попечительлек органы белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки;

бәяләмә проектын (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатны) үзгәртеп рәсмиләштерә.

үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проектын (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатны) кул кую өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән бәяләмә проекты (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат).

3.9.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәгә (бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы хатка) имза сала һәм аны опека һәм попечительлек органы белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар карар проектын имзага җибәргәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат).

3.9.3. Опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә баш тарту турында хат бирә (җибәрә). Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә барлык документлар да кире кайтарыла һәм карарга шикаять белдерү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура 3.9.2 пунктчада каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат).

3.10. Дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны аша күрсәтү.

3.10.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алу өчен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.10.2. Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк аша дәүләт хезмәте күрсәтү дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.10.3. Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктән дәүләт хезмәте алу өчен документлар килгәндә процедуралар әлеге Регламентның 3.3-3.7 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

3.11. Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатны) үзгәртеп рәсмиләштерү элек бирелгән бәяләмәдә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатта) җибәрелгән техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатны) үзгәртеп рәсмиләштерү техник хатасы булган, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган документ (мондый документ бирелү очрагында) белән теркәлгән гариза (гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка 7 нче кушымтада китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.11.1. Опека һәм попечительлек органы белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки;

бәяләмә проектын (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатны) үзгәртеп рәсмиләштерә.

үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проектын (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатны) кул кую өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән бәяләмә проекты (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат).

3.11.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәгә (бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы хатка) имза сала һәм аны опека һәм попечительлек органы белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат).

3.11.3. Опека һәм попечительлек органы белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат) турында хәбәр итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат) турында хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклаудан һәм бетерүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр уздырудан, карарлар кабул итүдән һәм учреждение вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүдән тора.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча документларның проектларына хокукый экспертиза уздыру. Экспертизалар нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;

эш алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерүләр;

дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә гамәлләр кылуны

тикшереп тору максатларында опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырылырга мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре турында нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында карамаган өчен җаваплы була.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә опека һәм попечительлек органы эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Башкарма комитет хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – Башкарма комитетка, Башкарма комитет җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) Муниципаль берәмлек советына судка кадәр тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә белдерелә, КФҮ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – КФҮ гамәлгә куючыга.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне, 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән гарызнамәне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;»;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать

итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларда, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, КФҮ, КФҮ хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.4. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, __________________ муниципаль берәмлеге рәсми сайты (http://www.______.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин. КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, КФҮ рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, КФҮ, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә граждан хезмәткәренең яки муниципаль хезмәткәрнең, КФҮ, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының йә дәүләт хезмәткәренең яки муниципаль хезмәткәрнең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының йә дәүләт хезмәткәренең яки муниципаль хезмәткәрнең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган түләүләрне мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Башкарма комитетта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Ятим балалар һәм балалар оешмаларында торучы, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламентына 1 нче кушымта

Форма
Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2019 елның 16 гыйнварындагы 17 номерлы боерыгы белән расланган

Опека һәм попечительлек органына
___________________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

**Баланы (балаларны) гаиләгә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсен бирү турында гражданин гаризасы**

Мин, ____________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шул исәптән элегрәк булганнары, иялек килешендә)

_________________________________________________________________________________
(туган көне, ае һәм урыны)

Гражданлыгы _______________ Шәхесне таныклаучы документы: _____________________________

_________________________________________________________________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Яшәү урыны буенча адресы _______________________________________________________

_________________________________________________________________________________
(яшәгән урынын теркәү белән раслаган яшәү урынының тулы адресы күрсәтелә, ул булмаган очракта сызык куела)

_________________________________________________________________________________

Торган урын адресы ______________________________________________________________

_________________________________________________________________________________
(теркәү белән расланган яшәү урыны, шул исәптән теркәү белән расланган яшәү урыны, булган очракта тутырыла. Яшәү урынының тулы адресы күрсәтелә, ул булмаган очракта сызык куела)

Фактик яшәү урыны адресы _______________________________________________________

_________________________________________________________________________________
(фактик яшәү урыны адресы яшәү урыны адресы яки тору урыны белән туры килмәгән очракта йә теркәү белән расланган яшәү урыны һәм тору урыны булмаганда тутырыла)

_________________________________________________________________________________
(элегрәк яшәгән, шул исәптән Совет Армиясендә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт иткән, белем алган Россия Федерациясе субъектлары күрсәтелә)

Телефон номеры __________________________________________________________________
(булганда күрсәтелә)

Хөкем ителгәнлек һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты булуы (булмавы) турында мәгълүмат:

шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена, шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халык сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, шулай ук җәмәгать иминлегенә, кешелекнең тынычлыгына һәм иминлегенә каршы җинаятьләр өчен хөкем ителгәнем булмады һәм хөкем ителмим

шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена, шәхеснең женси кагылгысызлыгына һәм женси ирегенә, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халык сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, шулай ук җәмәгать иминлегенә, кешелекнең тынычлыгына һәм иминлегенә каршы җинаятьләр өчен җинаять эзәрлекләвенә дучар ителгәнем булмады һәм дучар түгел

авыр яки аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яки үтәлмәгән хөкемем юк

Гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар

| № | Фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) | Туган елы | Балага карата туганлык мөнәсәбәте | Кайсы вакыттан бирле теркәлгән һәм яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

- миңа баланы (балаларны) гаиләгә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирүегезне үтенәм

- миңа баланы (балаларны) гаиләгә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирүегезне үтенәм

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)

Торак шартлары, сәламәтлек торышы һәм эш характеры миңа баланы (балаларны) гаиләмә вакытлыча алу мөмкинлеген бирә.

Үзем турында өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне хәбәр итә алам:

___

(гражданинда балалар тәрбияләүдә кирәкле белем һәм күнекмәләр булуы, һөнәри эшчәнлеге турында мәгълүматлар, Россия Федерациясе территориясендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затлар өчен әзерлек узуы турында күрсәтелә)

___

Мин,

___,

(фамилиясе, исемен һәм атасының исемен (булган очракта))

әлеге гаризада һәм мин тапшырган документларда булган үземнең персональ мәгълүматларымны эшкәртүгә һәм куллануга ризалык бирәм.

___

___

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

- шәхесне таныклаучы документ күчермәсе

- ачык формада йогышлы авырулар яисә психик авырулар, наркомания, токсикомания, эчкечелек авыруларының булмавы турында 164/у номерлы формада дәва-профилактика медицина оешмасыннан белешмә

(ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга, опекага (попечительлеккә), тәрбиягә яки патронат гаиләгә алырга теләүче гражданнарга медицина таныклавы уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә)*

Башка документлар:

1.

2.

3.

Ятим балалар һәм балалар оешмаларында торучы, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламентына 2 нче кушымта

164/у номерлы исәпкә алу формасы

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2014 елның 18 июнендәге 290н номерлы боерыгы белән расланган

**Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга, опекага (попечительлеккә), тәрбиягә яки патронат гаиләгә алырга теләүче гражданнарга медицина таныклавы уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә**

Бирелгән көне___________________

1. Бирелгән ________________________________________

(медицина оешмасының исеме һәм адресы)

2. Бәяләмә тапшырыла торган органның исеме ____________________________________

________________________________________

3. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ________________________________________

(ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга, опекага (попечительлеккә), тәрбиягә яки патронат гаиләгә алырга теләүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

4. Җенесе (ир-ат/хатын-кыз) ________________________________________

5. Туган көне, ае, елы ________________________________________

6. Яшәү урыны адресы ________________________________________

7. Бәяләмә (кирәкмәген сызарга):

Затта баланы уллыкка (кызлыкка) ала алмаган, опекага (попечительлеккә) кабул итә, тәрбиягә яки патронат гаиләгә ала алмаган авырулар булуы (булмавы) ачыкланды.*

Табиблар комиссиясе рәисе: ________________________________________

(Ф.И.А.)

_________________________

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
| | (имза) | (дата) |
| | | М.У. |

Ятим балалар һәм балалар оешмаларында торучы, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламентына 3 нче кушымта

Форма
Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2019 елның 16 гыйнварындагы 17 номерлы боерыгы белән расланган

Опека һәм попечительлек органы бланкы
Акт төзү датасы

**Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданинның яшәеш шартларын тикшерү акты**

Тикшерү датасы «__»__________20__ел.

Тикшерү үткәргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), вазыйфасы________________

________________________________________________________________________________

Түбәндәгенең яшәеш шартлары тикшерелде ____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)

________________________________________________________________________________

Шәхес таныклаучы документы_________________________________________________________

________________________________________________________________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Туган датасы һәм урыны ____________________________________________________________

Яшәү урыны буенча адресы __________________________________________________________
(теркәү белән расланган яшәү урыны адресы)

Фактик яшәү һәм тикшерү үткәрү урыны адресы _______________________________________

________________________________________________________________________________
(фактик яшәү урыны адресы яшәү урыны адресы яки тору урыны белән туры килмәгән очракта йә теркәү белән расланган яшәү урыны һәм тору урыны булмаганда тутырыла)

Белеме __________________________________________________________________________

Һөнәри эшчәнлеге _________________________________________________________________

________________________________________________________________________________
(эш урыны, адресын, билгән вазыйфасын, эш телефонын күрсәтеп)

Яши торган торак мәйданы __________________________________________________________,
(фамилиясе, исемен һәм атасының исемен (булган очракта))

______ кв. м. тәшкил итә, _____________ бүлмәдән тора, һәр бүлмәнең үлчәме:

________кв. м,_____________кв. м,________кв. м, ___ катта, ________катлы йортта.

Йортның сыйфаты (аерым алганда, кирпечтән, панельдән, агачтан; яхшы хәлдә, тузган, авария хәлендә; бүлмәләр коры, якты, үтеп керерлек, тәрәзәләр саны)

___

___

___

Йортны һәм торак мәйданын төзекләндерү (аерым алганда, суүткәргеч, канализация, нинди җылылык, газ, ванна, лифт, телефон) ___________________________________________

___

Торак мәйданның хуҗасы (яллаучы) булып тора

___

___

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданинга карата туганлык дәрәҗәсе)

Торак бинадан файдалану хокукын, торак бинадан файдалану хокукы срогын раслый торган нигезләр ___________________________________________

___

(торак урыны башка затлар милкендә булган очракта тутырыла)

Торак мәйданның санитар-гигиеник торышы (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнерлек түгел):

___

Балага йоклау, уеннар, дәресләр, шәхси әйберләр өчен аерым бүлмә, почмак булу

___

___

Торак мәйданда яшиләр (гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән һәм (яисә) фактик яшәче кешеләр)

| **Фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)** | **Туган елы** | **Эш урыны, вазыйфасы яки уку урыны** | **Туганлык мөнәсәбәте** | **Әлеге торак мәйданда кайчаннан бирле яши** |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

Гражданинның гаилә әгъзалары арасында барлыкка килгән мөнәсәбәтләр ______________________

___

(аерым алганда, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрнең холкы, балалар белән, балалар арасында үзара аралашу үзенчәлекләре)

___

Гражданинның баланы (балаларны) үзенең гаиләсенә вакытлыча тапшыру өчен мотивлары

___

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Тикшерү уздыруның өстәмә белешмәләре (аерым алганда, гаиләнең составы, яшен күрсәтеп балалар булу-булмавы, балалар белән аралашу тәҗрибәсе, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр, якын туганнар булуы һәм баланың (балаларның) гаиләгә вакытлыча кучүенә аларның мөнәсәбәте; башка балаларны гражданин гаиләсенә вакытлыча урнаштыру тәҗрибәсе; гражданинда балалар тәрбияләүдә кирәкле белемнәр һәм күнекмәләр булуы; гражданинның уллыкка алучы яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсе булу; Россия Федерациясе территориясендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итү нияте булган затларның әзерлек узуы турында мәгълүматлар)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Гражданинның яшәеш шартлары ______________________________________________

______________________________________________________________________________
(конкрет хәлләрне күрсәтеп, канәгатьләнерлек/канәгатьләнерлек түгел)

Комиссия рәисе: ______________________________________________
(Ф.И.А.)

______________________ ______________________ ______________________
(имза) (дата)

М.У.

Ятим балалар һәм балалар оешмаларында торучы, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламентына 4 нче кушымта

Форма
Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2019 елның 16 гыйнварындагы 17 номерлы боерыгы белән расланган

Опека һәм попечительлек органы бланкы
Бәяләмә төзү датасы

**Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданин гаиләсенә баланы (балаларны) вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсе**

Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) ________________________________________

______________________________________________________________________________

Туу датасы ____________________________________________________________________

Яшәү урыны адресы ______________________________________________________________
(теркәү белән расланган яшәү урыны адресы)
______________________________________________________________________________

Фактик яшәү урыны адресы _________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(фактик яшәү урыны адресы яшәү урыны адресы яки тору урыны белән туры килмәгән очракта йә теркәү белән расланган яшәү урыны һәм тору урыны булмаганда тутырыла)

Гаиләне сыйфатлау (аерым алганда, гаиләнең составы, яшен күрсәтеп, балалар булуы, балалар белән аралашу тәҗрибәсе, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр, якын туганнары булу һәм аларның баланы (балаларны) гаиләгә вакытлыча тапшыруга мөнәсәбәте)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Белеме һәм һөнәри эшчәнлеге _________________________________________________________

Сәламәтлек торышына сыйфатлама (гомуми сәламәтлек торышы, баланы (балаларны) гаиләгә вакытлыча тапшыруга комачаулый торган авыруларның булмавы)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Баланы (балаларны) гаиләгә вакытлыча тапшыру мотивлары _______________________________

___

Гражданин тапшырган документларда түбәндәгеләрнең булуы _______________________________,
(фамилиясе, исемен һәм атасының исемен (булган очракта))
баланы (балаларны) аның гаиләсенә вакытлыча тапшыруга каршы килә торган шартлар

___

(юк/бар, конкрет хәлләрне күрсәтеп)
Гражданин гаиләсенә баланы (балаларны) вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә

___

___

(фамилиясе, исемен һәм атасының исемен (булган очракта))

___

(мөмкин/гражданинның торак урынында тормыйча мөмкин/сәбәпләрен күрсәтеп, мөмкин түгел)

___

(Ф.И.А.)

___ ___ ___
(имза) (дата)

М.У.

Ятим балалар һәм балалар оешмаларында торучы, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ граждannar гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламентына 5 нче кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен һәм аны күрсәткәндә агымдагы контрольлек өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Бүлек башлыгы | (8-8____) _________ | ______________@tatar.ru |
| Бүлек белгече | (8-8____) _________ | ______________@tatar.ru |

Татарстан Республикасының ________________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-8___) _________ | ___________@tatar.ru |

Ятим балалар һәм балалар оешмаларында торучы, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламентына 6 нчы кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге буенча блок-схема**



Ятим балалар һәм балалар оешмаларында торучы, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бертип административ регламентына 7 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты җитәкчесенә

Техник хата төзәтү турында гариза

Мин,_______________________________________________________________

*(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*

түбәндәге адрес буенча яши _______________________________________________

_______________________________________________________________

*(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)*

_______________________________________________________________

*(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,*

_______________________________________________________________

*документны биргән орган аталышы)*

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында торучы балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында ____________________________
карар датасы

№ __________ бәяләмәдә җибәрелгән _____________________________ техник хатаны
карар номеры

төзәтүегез хакында үтенәм.

Техник хатаны төзәтү турында мәгълүмат алуга риза__________________________

_______________________________________________________________

*(язмача, телефон аша, смс-хәбәр белән, электрон почта аша)*

«___» _____________ 20___ ел. ____________________ ____________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)